## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 3 В
Атнага: 1сәг.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга «Әдәби уку» предметын коммуникатив технология нигезендә укытуның үрнәк программасы (1 — 4 нче сыйныфлар)Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, 2017 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№ 1 педсовет протоколы, 31 август 2018 ел).

Дәреслек: ”Күңелле татар теле” ”. Дүртьеллык башлангыч мәктәпенең 2 нче сыйныф рус балалары өчен татар теле һәм уку дәреслеге. Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Г.М.Әхмәтҗанова . Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 ел.

### I.Әдәби уку буенча планлаштырылган нәтиҗәләр

### Әдәби укуга өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә башлангыч сыйныфларда әдәби укуны укытуныңнәтиҗәләре билгеләнде.

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр***

- үзе яшәгән туган җирнең һәм зур ватанның берлеге, бердәмлегенә карата хөрмәт хисләре тууу;
- шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караштa булу;
- әхлаклылык һәм гуманизм кебек гомумкешелек принципларын, гаилә һәм мәктәп кыйммәтләрен хөрмәт итү һәм аларны үтәүгә омтылу.

***Метапредмет нәтиҗәләр***

- уку максатын (сөйләм бурычын) аңлап, аңа тәңгәл килерлек мәгълүматны сайлый белү;
- гомуми уку күнекмәләренә ия булу һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу;
- үз эшчәнлегеңне планлаштыру, аны контрольдә тоту һәм бәяли белү;
- укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу;
- таблица, схема, кагыйдә формасында бирелгән белешмә материалдан файдалану;
- коммуникациягә керә белү сәләтләре булу;
- парларда, төркемнәрдә эшли белү күнекмәләре булу.

***Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре***

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча башлангыч мәктәпне тәмамлаучы түбәндәге күнекмәләргә ия була:

***Уку***

- татар сүзенең график образын аның авазлы образы белән чагыштыру;
- укуның орфоэпик һәм интонацион нормаларын белү;

– өйрәнелгән материалга нигезләнгән кечкенә күләмле текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле итеп һәм әйтелеш нормаларын саклап уку;
– тексттан кирәкле мәгълүматны табу;
– укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясау;
– контекст нигезендә таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.

***Сөйләү***

– программа кысаларында сөйләм бурычына туры килгән лексик-грамматик материалны кулланып, әңгәмәдәшең белән контактка керү: сөйли, сорый белү; сөйләмне башлый, дәвам итә, төгәлли белү;
– телдән монологик сөйләм (тасвирлау, хикәяләү, фикер йөртү) күнекмәләренә ия булу; орфоэпик нормаларны үтәү;
– укыганның эчтәлеген сөйләү, эчтәлеккә карата фикереңне әйтә белү;
– текстны үзгәртеп, аналогик текстлар төзеп сөйләү;
– көндәлек аралашу ситуацияләренә бәйле сөйләм этикеты үрнәкләрен гамәли үзләштерү (сәламләү, саубуллашу, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, үтенеч белдерү);
– сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, гади диалогларда катнашу;
– предметны, персонажны яки рәсемне тасвирлау.

***Тыңлап аңлау***

– аралашу барышында укытучының һәм сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау, вербаль яки вербаль булмаган рәвештә җавап кайтару;
– тыңлана торган тексттагы мәгълүматны аңлау, аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

***Язу***

тексттан сүзләрне, сүзтезмәләрне, гади җөмләләрне күчереп язу;
– үрнәк буенча бәйрәмгә чакыру язу;
– үрнәк буенча дустыңа хат язу;
– сөйләм бурычын аңлап, кыскача үз фикереңне язмача белдерү.
– текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;
–терәк сүзләр ярдәмендә кечкенә хикәя төзеп язу;

## II.Укыту предметының эчтәлеге

| Тема | Тема буенча билгеләнгән тематик эчтәлек |
|---|---|
| **Белем бәйрәме** | “Беренче сентябрь» тексты.<br>“Без диктант яздык” тексты.<br>М. Галләмова. ”Чын иптәш”.<br>Ш.Галиев. ”Онытылган”.<br>“Китапханәдә” тексты.<br>Г.Зәйнәшова. «Бер атнада ничә көн?” |
| **Көндәлек режим** | “Минем көндәлек режимым” темасына сөйләшү. М.Җәлилнең ”Сәгать” шигыре. |
| **Ашхәнәдә** | “Ашханәдә” тексты.<br>Б.Рәхмәт ”Аш вакыты”.<br>Ш.Галиев. ”Кунаклар” |
| **Без әти-әниләргә булышабыз** | Г.Тукайның биографиясе.<br>Г.Тукай. “Безнең гаилә”.<br>Ә.Бикчәнтәева. ”Дәү әнием” |
| **Туган якка кыш килде** | Җ. Тәрҗеман. “Яшел чыршы”<br>Ә.Бикчәнтәева ”Салкын, саф һава”.<br>“Чыршы бәйрәме” тексты. |

| | |
|---|---|
| | “Тауда” тексты.<br>“Яңа ел бәйрәме”, “Кышкы уеннар”, “Каникулда”, “Дуслар” текстлары. |
| **Шәһәрдә һәм авылда** | “Татарстан—зур республика” тексты.<br>“Мин шәһәрдә яшим” тексты.<br>“Безнең авыл” тексты. |
| **Әдәпле булыйк** | «Тәмле сүзләр» тексты.<br>«8 нче Март- әниләр бәйрәме!» тексты.<br>“Трамвайда” хикәясе.<br>Дәрдемәнд. “Өч ул”. |
| **Кечкенә дусларыбыз** | М. Галләмова. “Дуслар” хикәясе.<br>М. Җәлил. “Маэмай”<br>“Кем нәрсә ярата?” әкияте.<br>«Минем песием» тексты. |
| **Күңелле җәй, ямьле җәй** | Г. Тукай. “Елның 4 фасылы”.<br>Б. Рәхмәт. “Матур җәй”.<br>Р. Фәйзуллин. “Җиләк кайда күп?”.<br>Х.Халиков. “Витаминлы аш”.<br>”Төсләр” әкияте.<br>Р.Миңнуллин. ”К” лар тулган бакчага”. |

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.

| № | Дәрес темасы | Укучыларның эшчәнлек төре | Үткәрү Вакыты план буенча | Үткәрү Вакыты факт буенча |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Белем бәйрәме.** | Текстның эчтәлеген аңлап, үз фикереңне әйтә белү. | 1.09 | |
| 2 | “Беренче сентябрь» тексты. | Әңгәмә, сәнгатьле уку | 8.09 | |
| 3 | М. Галләмованың ”Чын иптәш” хикәясе. | Шигырьне укып чыгу һәм тирәк сораулар буенча анализлау, | 15.09 | |
| 4 | “Китапханәдә” тексты. | Дәреслектә, биремнәр эшләп, текстның эчтәлегенә төшенү, геройларга бәяләмә бирү. | 19.09 | |
| 5 | Г.Зәйнәшеваның «Бер атнада ничә көн?” шигыре. | Әңгәмә, сәнгатьле уку | 26.09 | |
| 6. | “ Без диктант яздык” тексты | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 3.10 | |
| 7. | **Көндәлек режим.** | Уку, сораулар, биремнәр ярдәмендә эчтәлеген аңлау, фикер алышу. | 10.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | М.Җәлилнең ”Сәгать” шигыре. | Уку, сораулар, биремнәр ярдәмендә эчтәлеген аңлау, фикер алышу. | 17.10 | |
| 9. | Ашханәдә.“Ашханәдә”тексты. | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 24.10 | |
| 10 | Ш. Галиев «Кунаклар». | Текстның эчтәлеген аңлап, үз фикереңне әйтә белү. | 7.11 | |
| 11 | **Без эти-әниләргә булышабыз.** Г.Тукайның “Безнең гаилә” шигыре | Әңгәмә, сәнгатьле уку | 14.11 | |
| 12 | Ә.Бикчәнтәеваның ”Дәү әнием” шигыре | Шигырьне укып чыгу һәм тирәк сораулар буенча анализлау, | 21.11 | |
| 13 | “Акыллы малай” тексты. | Дәреслектә, биремнәр эшләп, текстның эчтәлегенә төшенү, геройларга бәяләмә бирү. | 28.11 | |
| 14 | “Азалия әнисенә булыша” тексты | Әңгәмә, сәнгатьле уку | 5.12 | |
| 15 | . Ж. Тәрҗеманның “Яшел чыршы” шигыре. | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 12.12 | |
| 16 | Ж. Тәрҗеманның “Чыршы” | Уку, сораулар, биремнәр ярдәмендә эчтәлеген аңлау, фикер алышу. | 19.12 | |
| 17 | Әминә Бикчәнтәева «Салкын саф һава» | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү | 9.01 | |
| 18 | «Тауда» тексты | Әңгәмә, тәрҗемә эше, сөйләү | 16.01 | |
| 19 | **Шәһәрдә һәм авылда.** «Татарстан—зур республика » тексты. | Монологик сөйләмгә чыгу, рәсемнәр буенча эш | 23.01 | |
| 20 | “Мин шәһәрдә яшим” | Әңгәмә, парлап эшләү. Сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау. | 30.01 | |
| 21 | “Безнең авыл” текстлар | Әңгәмә, сөйләү, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү | 6.02 | |
| 22 | **Әдәпле булыйк**. “Тәмле сүзләр” тексты. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү | 13.02 | |
| 23 | Туган көн” темасына диалоглар | Төрле биремнәр эшләү, әңгәмә, парлап эшләү | 20.02 | |
| 24 | 8 нче Март - әниләр бәйрәме тексты .*Без бүләкләр бирәбез* | Котлау язу белү, парлап эшләү. | 27.02 | |
| 25 | **Кечкенә дусларыбыз** | Укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 6.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26 | «Дуслар» хикәясе | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, төрле биремнәр эшләү | 13.03 | |
| 27 | Муса Җәлил «Маэмай» | Укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 20.03 | |
| 28 | .«Минем песием» хикәясе | Хикәяне уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, төрле биремнәр эшләү | 10.04 | |
| 29 | **Күңелле җәй, ямьле җәй**. Г.Тукай "БУ кайчак була7" | Эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү | 17.04 | |
| 30 | «Җәй җитте» тексты. | Парлап эшләү, сәнгатьле уку. | 24.04 | |
| 31 | . "Җиләк җыям,как коям" уены | Биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү | 1.05 | |
| 32 | Р. М и ң н у л лин «К» л а р тулган бакчага» | Эчтәлек белән танышу, әсәрнең төп фикерен аңлату, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку. | 8.05 | |
| 33 | Йомгаклау тесты | Тәрҗемә итү. Текстка таянып сөйләү, сорауларга җавап бирү | 15.05 | |
| 34 | Йомгаклап кабатлау дәресе | Практик күнегүләрдә Белемнәрне куллана белү | 22.05 | |